СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД АГРЫЗ» АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ӘГЕРҖЕ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

21.12.2021 Әгерҗе ш. № 14-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы нигезендә КАРАР ИТТЕ

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмә;

муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге;

муниципаль торак контроленең төп күрсәткечләре һәм аның максатчан күрсәткечләре, муниципаль торак контроле өчен индикатив күрсәткечләр.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 28 сентябрендәге 11-1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Әгерҗе шәһәре” муниципаль берәмлеге Советының шәһәр төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык, транспорт һәм элемтә буенча даими комиссиясенә (Башаров Р.Р.) йөкләргә..

Совет рәисе
муниципаль берәмлек башлыгы Ә.Р. Вәлиев

Совет муниципального образования «Город Агрыз» «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы ИНН 1601002430

Расланган
муниципаль Совет карарына